| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА СТАРОГРИШКИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,<br>Менделеевский район, Республика<br>Татарстан, 423642 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ<br>Яшьләр ур, 1 йорт,<br>Иске Гришкино авылы, Менделеевск<br>районы,<br>Татарстан Республикасы,423642 |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

7 ноябрь 2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 18 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Җыен уздыру урыны итеп Иске Гришкино авылы, Яшьләр урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Иске Гришкино авыл мәдәният йортын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

“2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләргә. I-II төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышы тыл ветераннарын, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, 18 яшькә кадәр тәрбиядә балалары булган аз керемле күпбалалы гаиләләрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, Россия Армиясе сафларына срок хезмәткә чакырылган гражданнарны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?”

«1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу, агачларны кисү)"»

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту, вак таш сатып алу, Куйбышев, Ленин, Азин, Яңа урамнар буйлап юлларга вак таш җәю, зиратка юл, су алу манарасына юл салу, транспорт хезмәтләре күрсәтү (автогрейдер хезмәтләре күрсәтү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Иске Гришкино авыл җирлеге»бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы К.И.Алексеев